«Имамнар халык белән аралашудан курыкмасын»

Күренекле дин галиме Шиһабетдин Мәрҗани: «Өч әйбер диндә юк, әмма динне саклый. Боларның берсе – милли тел, икенчесе – милли кием, өченчесе – милли гореф-гадәт», – дип әйткән. Милләтебезне, телебезне саклап калуга дин әһелләре дә үзләреннән зур өлеш кертә ала. Татарларның милли йөзен саклап калу белән без милләтебезне һәм халкыбызны саклауга да ирешәчәкбез. Казанда узган VIII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумында әлеге фикер еш яңгырады.

4 БИТ

Казан – йөгерүче башкала

Бу якшәмбе Казан халкы йөгерергә чыкты. «Казан марафоны» 10 мең кеше җыйды, шәһәр Россиянең иң яхшы йөгерүче башкаласына әйләнде.

8 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри Казан

татмедиа

Сишәмбе | 23.05.2017 | №54 (5816)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

КҮҢЕЛ ҖЫЛЫНЫРГА СӘБӘП БАР: МАЙ САЛКЫН БУЛСА, ИКМӘК УҢА

Шомырт чәчәк атканда, салкын була, дигән борынгылар. Быел исә салкын көннәр май буе дәвам итә. Җәйне кайчан көтәргә? «Татар-информ»да узган матбугат конференциясендә синоптиклар һава торышы турында фаразлары белән уртаклашты.

Зөлфия Хәлиуллина фотосы

Эльвира МОЗАФФАР

Белгечләр уздырган тәҗрибәләр күрсәткәнчә, һәр 30 ел саен һава торышының җылынуын күзәтергә була. Тик бу сөенерлек сәбәп түгел, ди синоптиклар.

– Аномаль һава температурасы үз чиратында көтелмәгән тискәре күренешләр китереп чыгара: буран, көчле яшенле яңгырлар, тайфуннар булырга мөмкин. Шуңа да климат нормада сакланса яхшы, – ди Казан Федераль университетының метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы җитәкчесе Юрий Переведенцев.

Быел май аендагы һава торышы климат нормасыннан артта калып бара. Галим әйтүенчә, хәзерге вакытта уртача һава температурасы 13 градус тирәсе булырга тиеш. Әмма әлегә көндезләрен генә азрак җылыта. Татарстанның Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе җитәкчесе Феликс Гоголь фаразлавынча, бүген 23 май көнне кырау төшәргә мөмкин, һава температурасының төнлә өч градуска кадәр суытуы көтелә. Көндез дә җылы дип булмый. Температура 9-15 градус. Халык аптырашта. Һава торышының кинәт үзгәреп торуы нәрсәгә бәйле? Махсус шул максатларда Россиядә климат атналыгы уздырырга булганнар. Шундый атналык чаралар кичә Татарстанда да башланып китте.

– Халык өчен һава торышының үзгәрешенә кагылышлы лекцияләр узачак, гидрометеорология станциясенә экскурсия уздыру да күздә тотыла. Атналык барышында авыл хуҗалыгы белгечләре, бакчачылар һәм башкалар синоптиклар белән элемтәгә чыга ала. Бу күп кенә мәсьәләләрне уртага салып сөйләшергә мөмкинлек бирәчәк, – ди Казан федераль университетының экология һәм география институты директоры Светлана Селивановская.

Күпләрне кызыксындырган «Көннәр җылытамы?» дигән сорауга синоптиклар төгәл генә җавап бирә алмадылар. Фаразлар буенча, июньдәге һава торышы нормага якын, ә июль гадәттәгедән җылырак килергә тиеш кебек. Әмма, алдан фаразлаулар бары 67 процентка гына туры килә, ди белгечләр. Ничек кенә булмасын, әле җәй килмәде.

– Урамда уртача һава торышы 15 градус җылы күзәтелгәндә генә чын җәй турында сөйләргә була. Әлегә салкынча, – ди Феликс Гоголь.

Хәер, атна урталарында җылыта башлар кебек. Синоптиклар әйтүенчә, 24 май көнне – 16-21, 25 майда 17-22 градус җылы көтелә. Урыны белән яшенле яңгырлар явуы да ихтимал.

Сынамышларга ышанып бетмәсәләр дә, синоптиклар үзләре аларга игътибар итәргә кирәк дип саный. Баксаң, хәзерге салкыннарның да уңай ягы бар икән. Май суык булса, икмәк уңа, ди халык әйтеме. Сынап карыйк.

Без дә «Бәллүр каләм»ле!

БӘЙРӘМ КАЙТАВАЗЫ

19 май – Татарстан Республикасының матбугат көнендә «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә «Бәллүр каләм – 2017» бәйгесе җиңүчеләрен билгеләделәр. Бәйгенең XX юбилей елы безнең газета өчен дә истәлекле булды. «Шәһри Казан» «Иң яхшы республика, шәһәр, район массакүләм мәгълүмат чаралары» номинациясендә җиңү яулады.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Гадәттәгечә, республика мәгълүмат чараларының иң дәрәҗәле бәйгесе югары рухта, зәвык белән үтте. Төрле номинацияләрдә җиңү яулаган журналистлар «Бәллүр каләм» сынын алырга сәхнәгә күтәрелгәндә, «La Primavera» Казан камера оркестры уйнап торды.

Дүртенче хакимият вәкилләрен һөнәри бәйрәмнәре белән Татарстанның Дәүләт Советы рәисе урынбасары – республиканың Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов тәбрикләде.

Римма Ратникова «Бәллүр каләм» бәйгесенең 20 еллык тарихын искә алып узды.

– Шушы 20 ел эчендә без барлыгы 590 «Бәллүр каләм» сыны тапшырдык. Иң беренче сыннар чыннан да бәллүр иде. Аны ясау өчен чималны Урал тауларыннан алып кайттык. Тора-бара ул тагын да камилләште. Бүләкнең рәвеше үзгәрсә дә, асылы үзгәрмәде. Бу – профессиональлек, журналист һөнәренә тугрылык билгесе, – диде Римма Ратникова.

– Быелгы бәйгә гадәти түгел. Без бүген журналистлар иҗатына 20 еллык нәтиҗә ясыйбыз. Җиңүчеләрнең сөенечләре белән күбрәк кеше уртаклаша алсын өчен, быел бәйгенең форматын аз гына үзгәрттек. Бүген залда ветераннардан алып, яшь журналистларга кадәр җыелган. Барысызны да күрүемә шатмын, – диде Айрат Зарипов.

Сүз уңаеннан, Татарстан премьер-министры Алексей Песошин республика массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә керткән өлеше өчен, Айрат Зариповка Татарстанның «Фидакарь хезмәте өчен» медален тапшырды.

Бәйгенең Гран-при иясенә журналистика өлкәсендә күп еллар хезмәт иткән «Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире Исмәгыйль Шәрәфиев лаек булды. Аңа «Лада Калина» автомобиле бүләк иттеләр. Ләкин үзе авырып киту сәбәпле, олы бүләкне Исмәгыйль әфәнденең кызы Айгөлгә тапшырдылар.

Быел жюри бәйге барышында 2 меңнән артык эш кабул иткән.

Алисә САБИРОВА.

«Сез әле үз бәягезне белмисез, ә бәлки без бәяләп бетермибездер»

Республика матбугат көнендә журналистларны Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлады һәм дәүләт бүләкләрен тапшырды.

– Татарстандагы барлык вакыйгаларның алдынгы позицияләрендә баручы журналистларның хезмәтен бәялибез, ирешелгәннәргә шатланабыз, эшли алмаган эшләр өчен борчылабыз. Сезгә җиңелләрдән түгел. Кайвакыт укучылар да тәнкыйтьли. «Тирәнрәк казынып язарга кирәк иде бу мәсьәләне», – диләр... Без Россиянең башка субъектларына караганда бәхетлерәк тә әле, чөнки Россия матбугат көнен дә билгеләп узабыз, үзебезнеке дә бар, – диде ул матбугат чаралары җитәкчеләре белән очрашу вакытында.

Фәрит Мөхәммәтшин Татарстан башкаласында бу көннәрдә күптөрле чараларның берьюлы узуы турында да искә төшерде. Чыннан да, Казанда узган атнада Конфедерация Кубогы, «Россия – ислам дөньясы» саммиты, Россия хәләл экспо халыкара күргәзмәсе, КФУда чаралар, Казан марафоны узды.

Фәрит Хәйруллович әйтүенчә, басма мәгълүмат – халыкка тәэсир итүнең мөһим коралы. Хөкүмәт журналистлар ярдәмендә халык белән аралаша, аның фикерен белә, республика кәефен тудыра, дип саный ул.

– Газетадагы материаллар, теле-радиодагы хәбәрләр, интернеттагы язмалар аша көн саен, сәгать саен республика халкы илебездә һәм дөньяда барган вакыйгалардан иң актуаль яңалыклар белән таныша. Авылларда да хәзер интернет бар. Хәтеремдә бер очрашу тирән эз калдырган. Сайлау кампаниясе вакытында Әгерҗе районында 80 яшьлек бер әби миннән: «Улым Мөхәммәтшин, АКШ Президенты кем була соң инде – Клинтонмы, Трампмы?» – дип сорады... Үзегезнең ни дәрәҗәдә кирәк икәнлегегезне чамалыйсызмы?.. Сез әле үз бәягезне белмисез. Ә бәлки без сезне бәяләп бетермибездер, – диде ул, журналистларга мөрәҗәгать итеп.

Бәйрәм көне булуга карамастан, Фәрит Мөхәммәтшин кайбер проблемаларга да тукталып узды. Аерым алганда, журналистларның кискен темаларны азрак күтәрүләре, журналист эзләнүләре аз булу, киберһөҗүмгә җавап бирердәй квалификацияле кадрлар әзерләү мәсьәләсенә тукталды. Шулай ук журналистлар династиясен әзерләүгә дә аерым бер игътибар бирелергә тиеш дип саный җитәкче. Болардан кала, Фәрит Мөхәммәтшин илдәге вазгыять, республикадагы хәл ителәсе проблемалар турында да үз фикерләрен җиткерде.

Зәһрә САДЫЙКОВА.

Балалар кулы – иң җылысы

Казанда язгы чордагы игелекле эшләр декадасы үтте. Әлеге чара кысаларында Горький исемендәге үзәк мәдәният һәм ял паркында, «Континент» паркында, Горки-Әмәт урманлыгында, Химиклар мәдәният сарае янындагы наратлыкта «Игелек ярминкәсе» оештырылды. Анда мәктәп укучыларының кул эшләнмәләре, тәм-томнар сатылды.

Ярминкәдә 5 миллион сум акча җыелган. Казан мэры Илсур Метшин шушы чараны оештыручыларга, мәктәпләр директорларына һәм ата-аналарга рәхмәт әйтте.

– Без төрле бәяләмәләрне ишетәбез, шул исәптән социаль челтәрләрдә дә, – диде мэр «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә. – Ләкин иң дөрес лакмус кәгазе ул – балаларның күз карашлары, аларның шушы хәйрия чарасында катнашырга омтылышы. Балалар моны белеп-аңлап башкарды. Бу зур акча. Эш акчада гына да, аның күләмендә генә дә түгел. Эшнең хәйрия эчтәлегендәге асылы һәм мөнәсәбәт – иң әһәмиятлесе.

Игелек ярминкәсендә 500 мәгариф учреждениесе катнашкан. Ярминкәләргә 50 мең кеше килгән. Илсур Метшин үзе Горки-Әмәт урманлыгындагы ярминкәдә булган.

Җыелган акча шәһәрнең, Добро Mail.Ru сервисы тикшерүен узгач, хәйрия фондларына күчереләчәк.

Киләчәк мөгаллиме нинди булыр?

Киләчәк укытучысын әзерләү – бүгенгенең көнүзәк проблемасы. Бу бер бездә генә түгел, чит илләрдә дә шулай булып кала бирә. Шуңа күрә дә дөньяның танылган галимнәре, бу мөһим мәсьәләне уртага салып сөйләшер өчен, Казанга, Федераль университетка җыелды.

tatar-inform.ru

23-25 май көннәрендә бирредә III халыкара форум уза. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында үткән матбугат конференциясенә форумның кунаклары: Майами университетыннан (АКШ) Дина Бирман, Дрезден техник университетыннан Аксель Герман һәм КФУның психология һәм мәгариф институтының халыкара эшчәнлек буенча директор урынбасары Роза Вәлиева журналистлар каршында чыгыш ясап, әлеге чараның әһәмияте һәм үзенчәлекләре турында сөйләделәр.

– Казанга Россиянең 28 һәм чит илләрнең 36 университетыннан галимнәр килде. Мондый форум бездә өченче тапкыр уза инде, – диде Роза Вәлиева. – Быелгысы башкаларыннан катнашучылар саны, бигрәк тә чит ил вәкилләренең күплеге белән аерылып тора. Докладлар белән чыгыш ясарга дөньякүләм рейтингларның беренче йөзлегенә кергән Оксфорд, Глазго, Дрезден, Майами, Люблян һәм башка университет галимнәре теләк белдерделәр. Форум кысаларында өч зур халыкара конференция узачак. Аларның берсе педагогларны укытуның дәвамлы булуына, икенчесе балалар өчен социаль тотрыклы һәм куркынычсыз тирәлек булдыруга, ә өченчесе мигрант балаларын укытучыларны әзерләүгә багышланачак.

Бу теманы ныклап өйрәнгән Дина Бирман һәм Дрезден университеты профессоры Аксель Герман әлеге проблеманың үзләрендәге чишелеше турында сөйләделәр.

– Германиядә, башка илләр белән чагыштырганда, укытучыларның хезмәт хакы югары. Ләкин шулай булса да, бу проблема бездә дә бик кискен тора, мәктәпләргә укытучылар җитешми. Чөнки илебездә укучылар саны кисәк кенә артты. Сәбәбе: демографик «шартлау» һәм иммигрантлар ташкыны. Без әлеге проблеманы чишүнең кайбер юлларын таптык шикелле. Галим булырга теләп, безнең вузга укырга кергән яшьләргә укытучылык һөнәрен дә өйрәтәбез. Аннары мәктәп тәмамлаучы яшьләрне генә түгел, урта (30-35) яшьтәгеләрне дә, укытучылыкка укырга килсәләр, хуплыйбыз гына, – диде Германия профессоры.

Бүген – укытучы белән укучы арасында гасырлар буе яшәп килгән стереотиплар да, стандартлар да җимерелгән чор. Мәгълүмат диңгезендә баштанаяк чумган бүгенге һәм киләчәк заман баласын укыту бары тик үзара ихтирамга нигезләнгәндә генә яхшы нәтиҗәләр бирәчәк. Дөнья университетларында киләчәк укучыларның булачак мөгаллимнәренә шуны төшендерергә тырышалар. Казанда да сүз шул хакта барачак.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Татарстан – «WorldSkills»та икенче

15-19 май көннәрендә Краснодар шәһәрендә узган «Яшь профессионаллар» V милли «WorldSkills Russia – 2017» чемпионатының команда зачетында Татарстан II урынга чыкты. Республика барлыгы 31 медаль яулады. Беренчелектә – Мәскәү, өченче урын Краснодар өлкәсенә эләкте.

Республика исеменнән ярышларда 16-22 яшьлек 81 студент катнашты. Алар – чемпионатның төбәк этабы җиңүчеләре. Татарстан командасы «Мәгълумати кабель челтәрләр», «Эшмәкәрлек», «Йөк машиналарына хезмәт күрсәтү», «Медицина һәм социаль хезмәт», «Сәнәгать робот техникасы», «Флористика», «Ювелир эше», «Лаборатор медицина анализы», «Башлангыч сыйныф укытучысы», «Тавыш режиссеры», «Кирпеч салу», «Балта остасы», «Мәктәпкәчә тәрбия бирү», «Автогрейд белән идарә итү», «Физик культура һәм спорт», «Җитештерү өлкәсендә команда белән эшләү» кебек 16 төрле номинация буенча беренчелектә.

21 яшьлек Тимур Шершнев Алексеевск районында автогрейдер йөртүче булып эшли. Ул да илнең иң яхшы эшчеләренең берсе.

– Чемпионатта катнашырга баш механигым Андрей Абясев тәкъдим итте. Миңа «Worldskills»ның барлык этапларын үтү дә ошады. Кызык, үзенчәлекле, истә калырлык вакыйга. Катнашучылар да, көндәшләрем дә бик күп иде. Мин алар белән күбрәк аралашырга, дуслашырга тырыштым, – ди егет.

Татарстанның мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Андрей Поминов, ярышларда республика дәрәҗәле чыгыш ясады, ди.

– 2016 елда Татарстан чемпионатта өченче иде. Быелгы икенче урын безнең өчен зур казаныш. Киләчәктә беренчелеккә күтәрелү өчен бөтен мөмкинлекләребез дә бар, – диде ул.

Әлеге чемпионатта җиңү яулаган студентлар Россиянең «Worldskills» җыелмасының киңәйтелгән составына керә. Алар быел – Абу-Даби шәһәрендә узачак дөнья ярышларында, ә 2018 елда Будапештта булачак EuroSkills чемпионатында катнаша.

Шулай ук республика мәктәп балалары арасында узган «JuniorSkills» бәйгесендә дә икенче урынга чыкты.

ҖӘЙ-2017

Шәһәр Башкарма комитетының гражданнарны яклау идарәсе җитәкчесе Фердинад Тимурханов «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә хәбәр иткәнчә, хәзер комлыкларны җыештыру һәм водолазлар ярдәмендә су төпләрен тикшерү-чистарту чаралары күрелә.

Бишмәт киеп, су коенмагаек

Казанда 1 июньнән коену сезоны ачыла

Муниципаль комлыкларда, шулай ук су буенда ял рөхсәт ителгән урыннарда 1 июньнән 30 августка кадәр иртәнге сәгать сигездән кичке тугызга кадәр ОСВОД коткаручылары һәм бер медицина хезмәткәре эшләячәк.

– Комлыкларда ял итүчеләр өчен суда иминлек дәресләре үткәреләчәк, белешмә китапчыклар таратылачак. Муниципаль комлыкларда соңгы биш елда бер кешенең дә суга батып үлүенә юл куелмады. Узган елгы коену чорында 19 кеше коткарылды, шуның дүртесе балалар иде. Комлыкта 124 кешегә ашыгыч медицина ярдәме күрсәтелде. Җәйге сәламәтләндерү лагерьларында балаларның су коенуы махсус әзерлекле коткаручылар күзәтчелегендә генә оештырылачак, – диде Фердинанд Тимурханов.

Чыгыш ясаучының фикерләрен мэр Илсур Метшин да куәтләде.

– Елга һәм күл буйларына метр саен коткаручы бастырып чыгып булмый, шунлыктан рөхсәт ителгән урыннарда гына коенырга кирәк. Ата-аналар, өлкәннәр су буйларында балаларга бик игътибарлы булсыннар иде. Балалар күз уңыннан ычкындырылмасын. Муниципаль комлыкларда суда батып үлүгә юл куелмавы бик яхшы. Быел да коену сезоны имин узсын, – диде мэр.

22 май көнне Казанда һава температурасы 5-10 градус кына җылы иде. Синоптикларның фаразларына караганда, июнь аеның беренче декадасында да һава температурасы +16 градустан артмаячак. Ләкин фараз ул фараз, ә без яр буйларына барырга әзер булып торыйк.

Казанда су коену өчен әзерләнелгән муниципаль комлыклар

«Локомотив» – Идел елгасы, «Казан» тимер юл вокзалы артында;

«Тирән күл» – («Озеро Глубокое»), Юдино бистәсе;

«Түбән күл» («Нижнее озеро»), Урман аръягы бистәсе, «Комсомол» – («Комсомольское»), Дәрвишләр бистәсе.

Яр буйларындагы ял урыннары

Аккош күле – Урман аръягы бистәсе, Киров районы;

«Изумрудное» – Юдино бистәсе; Җиңү паркындагы күл – Яңа Савин районы.

Дамир БӘДРИЕВ.

Казан шәһәре мэриясе, әнисе **Егорова Аграфина СЕМЕНОВНА** вафат булу сәбәпле, «Ак Барс» Холдинг компаниясе»нең генераль директоры Егоров Иван Михайловичның тирән кайгысын уртаклаша.

«Имамнар халык белән аралашудан курыкмасын»

Күренекле дин галиме Шиһабетдин Мәрҗани: «Өч әйбер диндә юк, әмма динне саклый. Боларның берсе – милли тел, икенчесе – милли кием, өченчесе – милли гореф-гадәт», – дип әйткән. Милләтебезне, телебезне саклап калуга дин әһелләре дә үзләреннән зур өлеш кертә ала. Татарларның милли үзаңын саклап калу белән без милләтебезне һәм халкыбызны саклауга да ирешәчәкбез. Казанда узган VIII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумында әлеге фикер еш яңгырады. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та чыгышында шуңа басым ясады.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Ел саен шушы форумга җыелып, динебезне генә түгел, телебез, гореф-гадәтләребезне саклауга кагылышлы мәсьәләләр турында сөйләшәбез. Әлеге уңайдан форумның әһәмияте аеруча зур. Үзара танышу, аралашу, тәҗрибә уртаклашу, борчыган проблемаларны хәл итү юлларын эзләү мәйданчыгы да булып тора ул. Милләтебезне саклап калуда без сезгә ышанабыз. Үзебез турында үзебез кайгыртмасак, моны безнең өчен беркем дә эшләмәячәк, – дип мөрәҗәгать итте ул форум кунакларына.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да аның сүзләрен хуплады.

– Без – Россиянең татар дин әһелләре – мәдәниятебезне, телебезне һәм милли үзенчәлекләребезне саклау өчен җаваплы. Быел Болгар ислам академиясе сафка басачак. Ул киләчәктә бөтендөнья ислам мәгариф үзәгенә әверелер дип ышанабыз. Белем алу – һәр мөселманның бурычы. Әбү Хәнифә хәзрәтләре: «Аллаһ үзенең колларыннан галимнәрне хөрмәт итә», – дигән. Безгә динебезне дә, телебезне дә яхшы белгән галимнәр кирәк, – диде ул.

Түбән өлкәсеннән делегат булып килгән Фатих хәзрәт Гарифуллин да телебезнең киләчәге өчен борчыла.

– Телнең югала баруы бигрәк тә Татарстаннан читтә сизелә. Яшьләребездә телне өйрәнүгә омтылыш юк. Коръән ашларына яки башка дини мәҗлесләргә баргач, Тукай һәм Җәлил шигырьләрен махсус яттан сөйләп күрсәтәм. Без, хәзрәтләр, дин белән бергә телебезне дә пропагандаларга тиеш. Телгә мәхәббәтне әнә шундый гади алымнар белән дә уятып була. Телне өйрәнергә кирәк дип сүз сөйләп кенә утырырга кирәкми, аны эш-гамәлләребез белән раслыйк, – ди ул.

Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры, тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев сүзләренчә дә, XVII-XVIII йөзләрдә дин әһелләре милләтебезне, телебезне, тарихыбызны һәм динебезне саклауны үз өстенә алган. Имамнарыбыз да шул иске традицияләрне торгызса иде, ди ул.

ГОШЕР КӨНЕН БУЛДЫРЫРГА КИРӘК

Ислам динен кабул итүнең 1000 еллыгы исемен йөрткән мәдрәсә ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин фикеренчә, соңгы елларда татар халкының күркәм гореф-гадәтләре кире кайта башлады. Күпләр нәсел шәҗәрәләрен барлау белән кызыксына, зиратларга барып каберлекләрне чистарту гадәтен торгызды. Гошер сәдакасын җыю матур гадәткә әверелде.

– Бу гореф-гадәт кенә түгел, фарыз гамәл дә. Татарстанның күп кенә районнарында ул хәтта бәйрәм төсендә үтә. Көзге уңыш җыеп алынганнан соң, халык ятимнәр йортларына, мәдрәсәләргә гошер сәдакасы китерә. Моңа тагын да аерым төс бирер өчен, октябрь аеның беренче якшәмбе көнен Гошер җыю көне итеп билгелик. 2 май көнен исә вафат булган милләт фидакарьләрен искә алу көне дип игълан итү идеясе дә бар. Безнең Диния нәзарәте вәкилләре, мәдрәсәбез шәкертләре катнашында инде унөч ел рәттән шушы көнне Иске Татар зиратына барып, остазларыбызны искә алу гадәте барлыкка килде. Бу көнне чит төбәкләрдән дә махсус килә башладылар. Халкыбыз өчен хөрмәтле затлар күмелгән каберлекләрнең интерактив картасын булдыру тәкъдимебез дә бар, – дип сөйләде ул.

ИМАМНАР ХАЛЫККА ЯКЫНАЙСЫН

Саратов өлкәсе Мөселманнары диния нәзарәте рәисе урынбасары Рушан Сәйфетдинов үзенең чыгышында дин әһелләренең халыктан ерак торуына борчылуын белдерде.

– Элек, революциягә кадәр, мәчетләр мөселман үзәкләре булып торган. Анда тормыш кайнаган. Бүген исә мәчет үз тормышы белән, мәхәллә халкы үз тормышы белән яши. Имамнарыбыз халык белән аралашудан курыкмасын иде, – ди ул.

Шөкер, мәхәллә халкы белән актив эшли торган мәчетләр бездә бар. Әлеге уңайдан Түбән Кама җәмигъ мәчете эшчәнлеген һәркемгә үрнәк итеп куярлык. Мәчетнең имам хатибы Йосыф хәзрәт Дәүләтшин сүзләренчә, аларның мәхәлләләре халык белән актив аралашып тора. Аларны мәчеткә җәлеп итү, динебезнең асылына төшендерү өчен бик күп кызыклы проектлар өстендә эшли.

– Пәйгамбәребез (с.г.с.): «Кешеләр арасында иң хәерлеләре – башка кешеләргә күбрәк файда китерә торганнары», – дип әйткән. Милләткә хезмәт итү, халыкка файда китерү – бүгенге көндә без дин әһелләренең мөһим вазифабыз булып тора. Кеше бәхетле чагында – балалары гаилә тормышына аяк басарга җыенганда да, яңа туган сабыена исем куштырырга да иң элек безнең янга мәчеткә килә. Тормышының иң авыр мизгелләрендә – әтисе яки әнисе вафат булгач та, «хәзрәт, нишлик» дип, мәчеткә шалтырата. Әйе, кешенең кайгылы, авыр чагы. Аз гына йомшак сүздән дә күңеле була, тынычланып кала. Нәкъ шул вакытта аның җанына вәгазь-нәсыйхәт үтә. Мәчетебез зур, халык күп килә. Баштагы елларда, дини мәрасимнәрне үтәгәндә, күп нәрсә ошамый иде. Мәсәлән, кеше телефоннан шалтыратып: «Бу шимбәдә – безнең никах, безгә мулла җибәрегез», – дип сорый. Никахланышырга теләүче егет белән кыз кемнәр? Әти-әниләре исән-саумы? Шаһитлары бармы? Бу хакта бер сүз дә юк. «Никах укырга мулла кирәк» – шуның белән сөйләшү тәмам! Хәзрәтләр бит янгынчылар төркеме түгел! Никахның, дини йолаларның дәрәҗәсен төшерә торган шуңа охшаш вакыйгалар безне бу мәсьәлә белән ныклап шөгыльләнергә этәрде дә инде. Без бабайлар белән җыелышып киңәшләштек тә, никахланышучыларга кайбер шартлар куярга уйладык. Беренчедән, заявка-чакыруларны телефоннан кабул итүне туктаттык. Гаилә корырга телиләр икән, мәчеткә килсеннәр, үзләрен күреп сөйләшик. Икенчедән, парлар никах дәресендә булырга тиеш. Бу максаттан, никахланышучы парлар өчен атнага ике көн дәрес уздыру тәртибен керттек. Без ул дәресләрдә никах мәҗлесе тәртибе турында да сөйлибез. Боларны телефон аша заявка-чакыру алганда гына сөйләп-аңлатып бетереп булмый. Ә мәчеттә барысын да аңлатып бирәбез. Никах мәсьәләсендәге кебек үк, вафат булганнарны соңгы юлга озатканда да, элек еш кына авырлыкларга юлыга идек. Кайчакта бер көнгә унга якын мәет була. Урамда 20-30 градус салкынмы, коеп яңгыр явамы – чакырган җиргә барыбер чыгып китәргә кирәк. Кайвакыт бабайларны җиткереп булмый. Кайбер балалар аталарын, озату мәшәкатеннән котылу йөзеннән, моргларда гына юдыра башладылар. Моргта теләсә кем юган кешегә җеназа укымыйбыз дип, тавышлар да чыга башлады. Шуны күз алдында тотып, махсус җеназаханә төзеттек. Мөселман илләрендә андый үзәкләр күптән эшләп килә. Кешеләр бу проектны шулкадәр яратып кабул иттеләр, хәтта урыс җитәкчеләре: «Менә минем оешмада кешеләр үлсә, нишләтергә, ничек ярдәм итәргә белми идем, мин дә акча бирәм, төзегез генә» – дип хупладылар. Бу минем имамлык тәҗрибәмдә әҗәтсез эшләнгән бердәнбер объект булды, хәтта махсус автомашиналык та акча калды. Димәк, проект кирәкле булып чыкты, – дип, үзләренең тәҗрибәсе белән таныштырды хәзрәт.

Никах, исем кушу, Коръән уку, җеназа, вафат булганнарны искә алу мәҗлесләрен бер тәртиптә тоту өчен, мәчеттә дини мәрасимнәр үзәге дә оештырганнар. Әлеге үзәк мәчетнең бер бүлеге булып тора.

ДИНИ ТӘРБИЯ – АБЫСТАЙЛАР ҖИЛКӘСЕНДӘ

Имамнар форумына мәдрәсә мөгаллимнәре, абыстайлар да чакырылган иде. Мәчетләрдә мөгаллимлек кылучы абыстайлар яшь буынга әдәп-әхлак тәрбиясен бирә, дини тәрбия – алар җилкәсендә. Башкортстанның Мөслимәләр берлеге бу эшкә ныклап торып тотынган. Берлек рәисе Розалия Халикова сөйләвенчә, алар мәктәп укытучылары белән актив эшли башлаган.

– Теләге булганнарны «Ихлас» мәчетенә чакырып, башлангыч дини тәрбия бирәбез. Берьюлы 100әр кеше килергә теләк белдерә. Курсларда бик теләп укыйлар. Аннары алар, Башкортстанның Диния нәзарәте ярдәме белән, Башкорт дәүләт педагогика университетында курсларда укып, ислам белгечләре дипломы алалар. Шуннан әлеге шәкертләребез мәктәпләрдә әхлак дәресләрен укыта. Безгә хәтта Самара, Чиләбе, Саратов, Оренбург, Ульяновскидан да килеп укыйлар. Берлекнең эшчәнлеге киңкырлы. Эчкече хатын-кызларны һәрдаим вәгазьләп торабыз. Хастаханәләргә дә йөрибез. Авыру хатын-кызларга психологик ярдәм күрсәтәбез. Андый вакытта күпләр Аллаһны искә төшерә, күңеленә рухи дәва, тынычлык эзли башлый. Кирәк икән, дога укырга өйрәтәбез, намазга басарга ярдәм итәбез. Алга таба әле тагын кызыклы проектларыбыз бар, – ди ул.

«Болгар шәһәре Татарстанның искиткеч матур урынына әйләнде»

Фоторепортаж www.shahrikazan.com сайтында

ИЗГЕ ҖЫЕН

president.tatarstan.ru

20 май көнне Болгар шәһәрендә Изге Болгар җыены узды. Республика халкы өчен генә түгел, Идел буенда яшәгән барлык мөселман өммәте өчен дә үзенчәлекле бәйрәм ул. Шушы көнне 922 елда безнең халык Ислам динен кабул иткән. Бу исә Идел буе Болгарын сәяси, мәдәни, мәгариф, фән өлкәсендә тагын да ныгыткан. Болгар дәүләтенең чәчәк атуына китергән.

Болгар җирендә Татарстан Президенты җитәкчелегендәге рәсми делегация иң элек «Кол Гали» кунакханә комплексының төзелеш мәйданчыгын карап чыкты. Объектны Идел елгасы ярында 2015 елның язында төзи башладылар. Әлеге кунакханәдә СПА-комплекс, тренажерлар залы, бассейн, теннис корты, баскетбол һәм балалар уен мәйданчыклары, йөгерү һәм чаңгы трассалары, җир асты парковкасы бар. Проект XIV гасыр Ак Пулатына охшатып төзелә.

Рөстәм Миңнеханов Россия Үзәк Диния нәзарәте рәисе, Россия Баш мөфтие Тәлгать Таҗетдин, Татарстан Мөселманнары диния нәзарәте рәисе, республика мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин белән берлектә әле төзелеш барган Болгар ислам академиясе бинасын да карап чыкты. Уку йортында барлыгы биш кафедра эшләячәк. Гарәп теле һәм әдәбияты, татар теле һәм әдәбияты бүлекләре дә булачак.

Академиянең китап уку бүлмәсендә Рөстәм Миңнеханов мөселман дине әһелләре белән очрашты.

– 922 елда безнең бабаларыбыз Ислам динен хөкүмәт дине буларак кабул иткән. Без хәзер шушы җирлекне күтәрәбез. «Кол Гали» кунакханәсендә бик матур төзелеш эшләре бара. Быел тәмамлап булмасмы икән дип уйлыйбыз. Бер ел элек Болгар ислам академиясенә дә нигез салынды. Бүген аның эшен ни рәвешле 1 сентябрьдә башлап җибәрү турында сөйләштек. Аңарчы төзекләндерү, профессор-мөгаллимнәр составын билгеләү, студентларны кабул итү мәсьәләләрен хәл итәргә кирәк. Ул терроризмга каршы чара да булачак. Академия каршында Бөтенроссия мөселман галимнәре берлеген булдыру да перспективалы чара, – диде Президент.

Рөстәм Миңнеханов искәрткәнчә, академия – федераль проект, аны Россия Президенты Владимир Путин хуплады. Республика башлыгы зур акчалар керткән иганәчеләргә, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевкә, Владимир Путинга рәхмәтен җиткерде.

– Болгар шәһәре Татарстанның теләсә кемне чакыра алырлык искиткеч урынына әйләнде. Иң мөһиме – бу эшләр барысы да чын күңелдән алып барыла, – диде Президент.

Изге Болгар җыенында барлыгы 40 меңләп кеше катнашты.

Дин әһелләре форумы кысаларында, Казан ханнары – Олуг Мөхәммәт улы Мәхмүт хан һәм Мөхәммәт Әминнең җәсәдләре җир куенына иңдерү чарасы да узды. 1977 елда Казан Кремлендә табылган ханнарның каберләре мавзолей-төрбәгә урнаштырылды, дип хәбәр итә «Татар-информ» агентлыгы.

ФОТОХӘБӘР

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Казанның 1000 еллыгы алдыннан Казан Кремле ныклап өйрәнелә башлагач, Сөембикә манарасы тирәсендә Казан ханнары сөякләре табылды. Моңарчы алар Археология музеенда сакланды. Галимнәребез билдергәнчә, бу сөякләр – 1467 елда вафат булган Мәхмүт хан һәм 1518 елда вафат булган Мөхәммәт Әмин ханнныкы. Җәсәдләрне Казан Кремле территориясендә җирләделәр. Аларны күмү дини йоласында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Үзәк Диния нәзарәте рәисе баш мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, республика мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, соңгы елларда халкыбызның тарихына зур игътибар бирелә.

– Үзебезнең җирлек, халкыбызның, дин тарихына игътибар юнәлтәбез. Ханнарыбызның җәсәдләрен җир куенына урнаштырабыз. Бу күптәнге теләк, бүген ул тормышка аша. Мин археологларга, архитекторларга, дин әһелләренә рәхмәтлемен. Бу бик изге һәм кирәк эш, – дип мөрәҗәгать итте Президент.

«Кол Шәриф» мәчете каршында җеназа намазы укылганнан соң, Камил хәзрәт Сәмигуллин Коръән укыды һәм чыккан Коръәннәрне багышлау өчен дога кылды. Аннары җәсәдләрне төрбәгә алып кереп урнаштырдылар.

«Казан Кремле» музей-тыюлыгы баш архитекторы Рөстәм Зәбиров журналистларга хан җәсәдләренең күн белән тышланган агач табутларга җиргә салынганын, өстенә ком сибелгәнен, аннары өстән тагын 20 см бетонланачагын әйтте. Бер атна эчендә каберләрне өстән пыяла аша карап булачак.

– Мәхмүт хан династиядә иң беренче, иң икенче хан булган. Ул – Казан ханлыгын булдырган Олуг Мөхәммәт улы. Иң Олуг Мөхәммәт улын шундук тәхеткә утырткан, иң үзе кыска вакыт кына идарә иткәннән соң хан иткән, – дип сөйләде Рөстәм Зәбиров.

Ул яңа төрбәнең элеккесеннән аерылып торуын әйтте. Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы белән килештереп, янәсында җир астына керү юлы ясалганын билгеләп узды. Туристлар төрбәгә кереп, каберләрне махсус пәрдә рәвешендә куелган пыяла аша карый алачак. Шулай ук каберләрне пыяла аша өстән дә күреп булачак. Рөстәм Зәбиров табутларда казулар вакытында табылган орнаментлар төшерелгәнен әйтте.

ОТЧЕТ О ДЕЯТЕЛЬНОСТИ
Муниципального автономного учреждения дополнительного образования «Детско-юношеская спортивная школа г.Казани «Ак Буре»» за 2016 год

Утвержден Наблюдательным советом
Протокол № 2 от 15 мая 2017 года

№	Содержание информации	2014 год	2015 год	Отчетный 2016 год
1	2	4	5	6
